# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясындагы алтынчы өлешен (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; 1994, № 1 – 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12, (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгыннар һәм гадәттән тыш хәлләр турында хәбәрләр кабул итү өчен «112» ашыгыч оператив хезмәтләр чакыру бердәм номеры һәм янгыннар, гадәттән тыш хәлләр турында хәбәрләр кабул итү буенча федераль законнарда күрсәтелгән тәртиптә билгеләнә торган телефон номеры файдаланыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 12 августыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 18 мае
№ 35-ТРЗ